ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СТАРОЧУРИЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Новая, д.52, с. Старое Чурилино,
Арский муниципальный район, 422014

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ ЧҮРИЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Яңа урамы, 52 нче йорт, Иске Чүриле
авылы, Арча муниципаль районы, 422014

Тел. (84366)57-3-48, 3-06-09 факс (84366)57-3-48, 3-06-09 E-mail: Schur.Ars@tatar.ru.

# КАРАР

**19.07.2023 ел** **№ 16**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы "Иске Чүриле авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә йорт хайваннарын йөртү өчен билгеләнгән урыннарны билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 №131-ФЗ, «Хайваннарга җаваплы караш һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 27.12.2018 №489-ФЗ федераль законнар, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Иске Чүриле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә, Казан районара табигатьне саклау прокуратурасының 15.05.2023 № 02-06-2023/Прдп 221 күрсәтмәсен караганнан соң, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлеге территориясендә йорт хайваннарын йөртү өчен түбәндәге урыннарны билгеләргә:

1.1. милек иясенең файдалануында яки милкендә булган җир кишәрлекләре;

1.2. кеше күп җыелмый торган авыл җирлеге территориясе, бушлыклар, торак сектор һәм җәмәгать урыннары артында аларның хуҗалары күзәтүе астында борынчак һәм бәйләвечтә:

-Иске Чүриле авылының төньяк-көнбатыш өлешендә, Мәктәп урамыннан 100 метр ераклыкта;

-Штерә авылының көньяк-көнбатыш өлешендә Совет урамыннан 100 метр ераклыкта;

-Ашабаш авылының көньяк-көнчыгыш өлешендә Күпер урамыннан 100 метр ераклыкта;

-Татар Кәдрәге авылының көньяк-көнчыгыш өлешендә Аркылы урамннан 50 метр ераклыкта;

-Венета авылының көньяк-көнчыгыш өлешендә Яшьләр урамыннан 100 метр ераклыкта;

-Михайловка поселогының көньяк-көнчыгыш өлешендә Тау өсте урамыннан 100 метр ераклыкта;

-Ермоловка авылының көньяк-көнчыгыш өлешендә Елга арты урамыннан 50 метр ераклыкта;

-Красная Горка авылының көньяк-көнчыгыш өлешендә Бакча урамыннан 50 метр ераклыкта.

Бу территорияләрдә «Йорт хайваннарын йөртү» дип язылган такталар урнаштырырга.

2. Йорт хайваннарын йөртү гражданнарның, хайваннарның иминлеген, физик һәм юридик затларның мөлкәтен саклау шартларында башкарылырга тиеш.

2.1. Этне йөртү аның озынлыгы этнең үз-үзен тотышын контрольдә тотарга мөмкинлек бирә торган бәйләвеч (этне тотып торучы башка җайланма) кулланып башкарылырга тиеш (исемлеге Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган әлеге карарның 5 пункты нигезләмәләре кулланыла торган потенциаль куркыныч этләрне йөртүдән тыш).

3. Рөхсәт ителми:

3.1. Йорт хайваннарын балалар һәм спорт мәйданчыкларында, парклар, скверлар территориясендә, халык күпләп ял итү урыннарында, балалар, мәгариф һәм дәвалау учреждениеләре, мәдәният, кибет объектларына якын территорияләрдә ирекле йөртү, хайваннар белән бергә йөрү өчен махсус объектлардан тыш.

3.2. 3.1 пунктның гамәлдә булуы сукырларга юл күрсәтүче этләргә кагылмый.

3.3. Этләрне йөрткән вакытта караучысыз калдыру;

3.4. Этләрне алкоголь, наркотик яки токсик исерек хәлдә булган, шулай ук яшьләре яки сәламәтлекләре аркасында этләрнең хәрәкәтләрен контрольдә тота алмаган һәм аларның агрессив тәртибен туктата алмаган затлар йөртү.

4. Йорт хайванын йөрткәндә, барлык очракларда да, хуҗа үзе белән экскрементлар җыю өчен кирәкле әйберләр алырга һәм шунда ук үзенең йорт хайваны артыннан, шул исәптән подъездлар, баскычлар, лифтлар, балалар мәйданчыклары, җәяүлеләр юллары, подваллар һәм торак йортлар һәм торак зоналарда гомуми файдаланудагы башка урыннарда экскрементларны җыештырырга тиеш.

5. Йөртү урынына карамастан, исемлеге Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган потенциаль куркыныч этләрне борынчаксыз һәм бәйләвечсез йөртү тыела, потенциаль куркыныч этне потенциаль куркыныч эт хуҗасына милек хокукында яки башка законлы нигездә караган киртәләнгән

территориядә йөртүдән тыш. Әлеге территориягә кергәндә мондый этнең булуы турында кисәтү язуы булырга тиеш.

6. Әлеге карар басылып чыккан көннән үз көченә керә.

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга һәм түбәндәге адреслар буенча мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка житкерергә: Татарстан Республикасы, Арча районы, Иске Чүриле авылы, Яңа урам, 52 йорт; Татарстан Республикасы, Арча районы, Венета авылы, Үзәк урам, 13 йорт; Татарстан Республикасы, Арча районы, Ашабаш авылы, Комсомол урамы, 4а йорт; Татарстан Республикасы, Арча районы, Штерә авылы, Совет урамы, 30Б йорт.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Иске Чүриле авыл җирлеге башлыгы Р. Т. Һидиятуллин